*Габделбари Баттал*

# ГАБДЕЛВӘЛИ ЯУШЕВ*

## Мөкаддимә[1] урынына

Троицки байларыннан вә хәйрат ияләреннән Габделвәли Яушевның тәрҗемәи хәлен «Асар»га дәрҗ итү[2], Ризаэддин хәзрәткә[3] матлуб[4] булганлыктан, шул тәрҗемәи хәл[5] өчен мәгълүмат җыйдырып, яки үзен тәртип иттереп җибәрүләре хосусында, хәзерге Яушевлар тиҗарәтханәсенең[6] патроны булган Муллагали әфәнде Яушевка хат язган; ләкин ни өчендер, бу хат җавапсыз калган. 1910 нчы елның җәендә мин Троицкига килгәч, Ризаэддин хәзрәтнең бу арзусын[7] Габделвәлинең угылларына сөйләдем. Алар, ошбу тәрҗемәи хәлне яздыруга карар биреп, бу хезмәтне миңа тапшырдылар. Мин моны, «Асар»га дәрҗ итәрлек рәвештә язып бетереп, инде җибәрдем дип торганда, «Асар» оригиналларының мосаддира[8] ителгәнен газеталарда укыдык.

Габделвәлинең бәгъзе балалары: «Аерым рисалә[9] итеп бастырсак ничек булыр икән?» – дидекләреннән, бу хосуста киңәш итеп, Ризаэддин хәзрәткә мәктүб яздым. Мәктүбемә каршы ошбу җавапны алдым: «Габделвәли тәрҗемәсен язып бетерүегез өчен шатландык. «Асар»ның ни вакыт кайтуы мәгълүм түгел, сәламәт кайтуы да шөбһәле. Кәгазьләре тегелмәгән, рәкымнар[10] куелмаган иде. Мөкаддимәсен язып тәмам итдекем соң: «Имде рәкымнарын иртә торгач куярым», – дия калдырып урыныма яттым, шул кичәдә мәгълүм афәт[11] килде. Иртә рәкымнарны тәртип итеп, сәгать 10 да үз хозурымда Бисмилла куйдырып, хәреф җыярга башлатмак хыялыннан идем, фәкать насыйп булмады. Холаса[12]: сезнең яздыгыңыз, иншалла, үзенә мөстәкыйль бер рисалә булырга ярар, булган нәрсә тик ятмасын, ихтимал, безнеке

---

* Баттал Г. Габделвәли Яушев. Наширләре: Габделвәли угыллары: Мөхәммәтгали, мулла Мөхәммәт вә Габделгазиз Яушевлардыр. Оренбург: «Вакыт» матбагасы, 1912. – 17 б. («Троицки байларыннан вә хәйрат ияләреннән» сериясе).

[1] мөкаддимә – кереш сүз.

[2] дәрҗ итү – теркәү, арага кертү.

[3] Фәхреддин (Фәхреддинев) Ризаэддин Фәхреддин улы (1859–1936), мәгърифәтче галим, тарихчы, дин белгече һәм җәмәгать эшлеклесе.

[4] матлуб – теләнгән, соралган нәрсә.

[5] тәрҗемәи хәл – биография.

[6] тиҗарәтханә – сәүдә йорты.

[7] арзусын – теләген.

[8] мосаддира – югары дәрәҗәле.

[9] рисалә – брошюра.

[10] рәкым – бит саны, номер.

[11] афәт – бәла-каза, бәхетсезлек.

[12] холаса – кыскасы.

кеби булмаса да, башка бер афәт килмәктән иминият юк. Шуның өчен басылуын муафыйк[1] күрер идем, ягъни бу көннән үзенә аерым рисалә ителеп басылсын. Кеше сүзеннән курыкмагыз, басылсын. Бүгенге кешеләр сүзләренә игътибар юк. Игътибар исә, киләчәктәгеләргәдер. Киләчәкләр рәхмәттән башка бер нәрсә дә әйтмәсләр».

Тәртип иткәнем ошбу тәрҗемәи хәлне хөрмәтле остаз Ризаэддин хәзрәткә җибәреп күрсәткән идем, ул лотфән[2] бәгъзе кимчелекләрен күрсәтеп аерым билгеләр куеп җибәрде. Аларны төзәттем. Дәхи рисалә шәкелендә[3] басылачак булгач, аерым-аерым сүз башлары ясарга вә бәгъзе нәрсәләр арттырырга туры килде. Габделвәли Яушев хакындагы мәгълүматның иң күп өлешен ахунд хәзрәт Рахманколый вә Мөхәммәт хәзрәт Бикматидән алдым. Ошбу мөхтәрәм өч затка чын күңелемнән тәшәккер[4] итәмен.

Ошбу рисаләгә сахибе[5] тәрҗемәнең рәсеме, имзасы, туган вә үлгән өйләренең рәсемнәре, аның киңәшчеләреннән ахунд Рахманколый вә шәех Зәйнулла Рәсүлинең рәсемнәре һәм Яушевлар салдырган Кустанай[6] мәчетенең рәсеме дәрҗ ителде.

*Г. Баттал[7].*
*Троицкий 1911 ел, 2 октябрь.*

## I

**Габделвәли Яушев**

*Бабалары вә анларның ватаннары – Троицкида Гайсадан таралган Яушевлар.*

**Габделвәли бин Әхмәтҗан бин Гайса бин Йосыф бин Бикбау бин Мортаза бин Морад бин Габдулла бин Дустмөхәммәт бин Ягуш бин Яуш[8].**

Бу затның балалары Казан өязендә Иске Мәңгәр[9] авылында көн иткәннәр. Троицкига Гайса Йосыф угылы күчеп килгән. Бу шәһәрдә булган Яушевларның һәммәсе шушы Гайсадан таралганнар: моның Фатыйма

[1] муафыйк – туры килгән, урынлы.

[2] лотфән – ярдәм йөзеннән, хуш күреп.

[3] рисалә шәкелендә – брошюра формасында.

[4] тәшәккер – рәхмәт белдерү.

[5] сахиб – ия, хуҗа.

[6] Кустанай – Казакъстандагы шәһәр, 1893–1895 елларда Николаевск исемен йөрткән.

[7] Баттал Габделбари Габдулла улы (1880–1969), тарихчы, филолог, журналист, җәмәгать-сәясәт эшлеклесе.

[8] Троицкида Габдулла Хәкимҗан угылы Яушев кулындагы русча тәртип ителгән шәҗәрәдән (родословное князей Яушевых) күчерелде. Шәҗәрәнең астында язылган русча язуларның укырга мөмкин булган кадәресеннән бу шәҗәрәнең 1856 нчы миладида Габделвәлинең бабасы Гайса тарафыннан төзелдереп, Казан шәһәрендәге әллә нинди мәхкәмәләрдә тасдыйк вә тәэкид иттерелгәнлеге аңгарыла. Бу язуларның байтагын, кәгазь вә чүпрәкләре белән бергә, тычканнар ашаган вә бөтен шәҗәрә майланып вә пычранып беткән. Габдулла әфәнде аны миңа әллә кайдан – кладовойдан эзләп табып бирде. (Автор искәрмәсе).

[8] Иске Мәңгәр авылы, Әтнә районында, район үзәгеннән 6 км көнчыгышрак, Ашытның сул кушылдыгы Симет елгасы бассейнында. Казан ханлыгы дәвереннән мәгълүм.

Габдерәфыйкъ кызы исемле хатынынннан: Әхмәтҗан, Мөхәммәтҗан, Хәкимҗан, Шакирҗан. Исмәгыйльҗан вә Зәкирҗан исемле угыллары; Гайшә, Зөһрә вә Гафифә атлы кызлары; Мәхбүбкамал исемле икенче бер хатынынннан Мөхәммәтлатыйф исемле бер угылы булган.

Мөхәммәтҗан бин Гайсаның Мөхәммәтгали, Мөхәммәтшаһ дигән ике угылы булган; болардан әүвәлгесенең хәяттә дүрт угылы вә бер кызы бар; Мөхәммәтшаһ бин Мөхәммәтҗан үзе дә хәяттә; балалары күп.

Хәкимҗан бин Гайсаның Габдулла вә Мөхәммәтвәли исемле ике угылы бар; Әшраф исемле кызы сахибе тәрҗемә Габделвәлинең тәхет никахында иде; Бәдәрсафа атлы кызы Троицкида Вәлишакир угылы нам кемсәгә бирелгән. Хәдичә исемле кызы элек, сахибе тәрҗемә Габделвәлинең Мәүдүдә исемле хатынынннан туган Габдерахман тәхет никахында булган; хәзердә Казанда Яңа Бистәдә имам Кәшшаф Тәрҗемани[1] тәхет никахында булып, бер хәяттәдер.

Шәкирҗан бин Гайсаның гакыйбе[2] юк. Бу – 1871 нче миладида ахунд Әхмәтхаҗи Рахманколый белән бәрабәр хаҗга барганда борадәре Хәкимҗан белән икесе бергә Мәдинә[3] белән Мәккә[4] арасында «Раян» дигән урында вафат вә шунда мәдфүн[5] булганнар.

Исмәгыйльҗан бин Гайсаның Маһибәдәр исемле бер кызы гына калган; әле хәяттәдер. Закирҗан бин Гайсаның гакыйбе юк.

Гайшә бинт Гайса вакыт илә Троицкида 2 нче мәхәлләдә имам булган Әхмәт[6] хәзрәтнең туганы Габделлатыйф Халит угылының тәхет никахында булган. Монын хәяттә бер кызы гына бар.

Зөһрә бинт Гайса Троицкида Габдерахман Габбас угылы дигән бер кемсәнең тәхет никахында булган. Монын хәяттә бер угылы ике кызы бар.

Гафифә бинт Гайса, Петропавелда ахунд булган Габделбарый Габбас угылы[7] Яушевка бирелгән. Аннан Габделваһап исемле угылы хәзер дә шул шәһәрдә имам вә ахундтыр.

---

[1] Тәрҗемани Кәшшаф (Тәрҗеманов Кәшшафетдин Кыяметдин улы) (1877–1943), дин һәм җәмәгать эшлеклесе, дин гыйлеме белгече. Репрессия чоры корбаны.

[2] гакыйбе – нәселенең дәвамы юк.

[3] Мәдинә, Согуд Гарәбстанында Мәккәдән 400 чакрым төньяктарак урнашкан шәһәр.

[4] Мәккә, Согуд Гарәбстанындагы шәһәр, Мөхәммәд пәйгамбәрнең ватаны. 7 нче гасырдан мөселманнарның изге шәһәре һәм хаҗ кылу урыны.

[5] мәдфүн – күмелгән, җирләнгән.

[6] Тәрҗемәи хәле «Асар»да язылгандыр.

[7] 2 нче кыйсем «Мөстәфадел-әхбар»ның 261–263 битләрендә шушы Габбас хәзрәтнең тәрҗемәи хәле язылган. Нәсебен: «Габбас бин Габдерәшит бин Әхмәт бин Шәкир бин Хәсән бин Котлыгмөхәммәт бин Ишмөхәммәт бин Дустмөхәммәт бин Багыш бин Яуш» дисә дә, русча язылмыш рәсми шәҗәрәдә ул «Яуш»ка менә бу рәвешчә илтеп тергәлгән: «Габбас, Габдерәшит, Хуҗа, Котлыгъәхмәт, Хөсәен, Хәсән, Дустмөхәммәт, Багыш, Яуш». Кайсының дөреслеген Алла белсен. (Автор искәрмәсе.)

Мөхәммәтлатыйф бин Гайсаның хәяттә Муллаәхмәт, Мулламөхәммәт исемле угыллары; Мәгъмүрә исемле бер кызы бар.

Әхмәтҗан бин Гайсаның Габделвәли (сахибе тәрҗемә), Мөхәммәтсадыйк, Мөхәммәтшәриф һәм Муллагали исемле угыллары; Газизә, Маһирә вә Маһитаб атлы кызлары булган.

Мөхәммәтсадыйктан Шакир исемле бер угылы; Маһруй вә Мөстүрә исемле ике кыз калган. Шакир вафат булып өч угылы, бер кызы калган. Маһруй белән Мәстүрә икесе дә иргә барганнар вә хәяттәдерләр.

Мөхәммәтшәриф 1906 нчы миладида сахибе тәрҗемә белән бер елда вафат булып, Мөхәммәтлатыйф исемле угылы, Мөнәвәрә исемле кызы калды.

Муллагали хәяттә булып бүгенге «Торговый дом борадәран Яушевлар» фирмасының патроны (олыгысы)дыр.

Газизә – Вәлитаһир угылы Уразаев нам кемсә никахында булган. Ул үлгәч, туганы Маһирә дә аңа барган. Газизәдән туган Мөхәммәтҗан Уразаев Ташкент шәһәрендә бер хәят булып, борадәран Яушевлар хезмәтендәдер. Маһитаб, хәзердә 2 нче мәхәлләдә имам, мулла Мөхәммәтзариф угылы Бикматовның тәхет никахында булып бер хәяттәдер.

## II

*Гайсаның мал табуы, изгелекләре вә торган йорты – Әхмәтҗанның үз алдына эш күрә башлавы – Хәкимҗанның аңа вә сахибе тәрҗемәгә ярдәме – Әхмәтҗанның хаҗ кылуы вә вафаты – сахибе тәрҗемә эш башында.*

Сахибе тәрҗемәнең бабасы Гайса, Троицкидан Бохарага[1] чыгып китеп анда чын гайрәт вә һиммәт белән кәсепкә тотынган, кәрван булып ком диңгезләре аркылы төрле шәһәрләргә юнәлә торган дөяләргә артыла[2] (йөкләнә торган йөкләрне бәйләү хезмәтендә вә башка хезмәтләрдә булынган). Аның шул рәвешчә берничә ел кәсеп итеп сәрмая[3] ясагач, Троицкига кайтып сәүдәгә тотынган: Минаунида[4] вә шәһәр эчендә дөкян – кибетләр ачкан; акрын-акрын игътибарлы вә инабәтле[5] сәүдәгәрләр рәтенә тезелсә дә, артык байый алмаган, тик угылы Хәкимҗан җитешкәч кенә яхшы ук дәүләт иясе булып киткән вә бай исемен алган.

Гайса, дәүләт иясе булганнан соң мәчетләрне карарга бик әһәмият бирә торган булган: 2 нче мәхәлләдәге мәчетне берничә мәртәбә тәгъмир[6] иттергән вә 3 нче мәхәлләдәге мәчетне бөтенләй үз кесәсеннән салдырган.

[1] Бохара – Урта Азиядәге иң борынгы шәһәрләрнең берсе.
[2] артыла – төялә, йөкләнә.
[3] сәрмая – төп капитал, акча.
[4] Минауни – алыш-биреш урыны.
[5] инабәтле – ышанычлы, таянычлы.
[6] тәгъмир – төзәтү, яңарту.

Ул вакытта шәһәрнең ул як очы, хәзерге Һәдиятулла Дивәзиев йортыннан да югарырак булган. Бинаән галәйһи[1], бу мәчет салынган урын буш дала, өстәвенә сазлык, сулы бер күләвек булган. Гайса бу күләвекне балчык вә таш белән тутырттырып шул җиргә мәчет салган. Ул чакта ул тирәдә татарлар да бик аз булган. Ләкин соңыннан килгән татарларның иң күп өлеше шул тирәгә җыелганнар. Бу көндә татарның иң күп булган урыны шул тирә булып, «шәһәрнең татар кыйсеме» дип аталадыр.

Гайсаның тормышы 2 нче мәхәлләдә булган. Аның торган йорты хәзер моның угылы Латыйф балалары милкендәдер. Ак буявы вә гомумән стиле – искелек вә борынгылыктан хәбәр биреп торадыр.

Гайса, сахибе тәрҗемәнең атасы Әхмәтҗанны аерып чыгарган. Аерылып чыккач, Әхмәтҗан үз алдына сәүдәгә тотынса да, ни өчендер алга китә алмаган. Атасы белән бергә торган Хәкимҗан, Әхмәтҗанның бу хәлен күреп, аны кызганган, вә Гайса карттан аңа файда уртакка мал биреп, Бохарага җибәрүне үтенгән; Гайса күнгән. Әхмәтҗан бер баруда ук, Бохарадан алып килгәне мамыктан бик зур файда иткән дә, яхшы гына сәрмая (сумма) ясаган. Шуннан соң, 1853 нче елда, Бохарага угылы Габделвәлине дә алып барган; Ташкентка да баргалап йөргәннәр.

Шул эшендә Габделвәлинең уяулыгын вә күзе ачыклыгын Хәкимҗан күреп, аны үз култыгына алган вә аңа тагы да зуррак эшләргә катышырга юллар ачкан. Шул рәвешчә, Габделвәли сәүдә эшләренә катышып, җиддият[2] белән эш күрә башлаганнан соң, Әхмәтҗан яхшы ук дәүләт иясе булып киткән. Ләкин соңыннан, ни өчендер, Әхмәтҗан «сынган», гайрәтле Габделвәли ата дәүләтен яңадан аякка бастырып, хәзерге Яушевлар байлыгына нигез салган.

Балалары эш башкара башлаганнан соң, Әхмәтҗан 1870 нче миладида ахунд Әхмәтхаҗи Рахманколый рәфәкатендә[3] хаҗга барып кайткан; 1875 нче ел февраль 5 ндә 57 яшендә вафат булган.

Әхмәтҗан вафат булгач, сәүдә эшләренең башында тагын да җиддият белән Габделвәли йөри башлаган; б201радәре Садыйк аңа ярдәмче булган; болар Шәриф вә Муллагали белән дүрт агай-эне бергә торганнар вә берлектә эш йөрткәннәр. Эшне дәхи[4] дә ныграк казыкка бәйләр өчен сахибе тәрҗемә үз фирмаларын «Торговый дом под фирмою Габделвәли Әхмәтҗанович Яушев с братьями» (Габделвәли Әхмәтҗан угылы Яушев вә борадәрләренең тиҗарәтханәсе) исемендә ясаган. Ләкин, соңыннан Садыйк болардан аерылып чыккан. Дәхи, Әхмәтҗанның хаҗга китмәстән элек сатып алган Болгари (күн)

[1] бинаән галәйһи – шуңа күрә.
[2] җиддият – тырышып, көч куеп.
[3] рәфәкать – юлдашлык.
[4] дәхи – тагын.

заводын Габделвәли зурайткан вә киңәйткән. 1881 нче елда паровой тегермән торгызганнар.

III

*Сахибе тәрҗемәнең туган тарихы вә йорты – анасы вә бабасы – хатыннары вә балалары – укыган җире вә остазлары, гыйлеме, фикере вә сәүдәгәрлеге – киңәшчеләре (шәех Зәйнулла Рәсүли вә ахунд Рахманколый).*

Сахибе тәрҗемә Габделвәли 1840 нче ел март 12 сендә Троицкида 1 нче мәхәлләдә Су Буе урамында баҗиче (Урта Азиядән килгән малларга тамга сугып торучы) Һибәтулла Хәмзә угылы йортында туган. Бу йорт бу көндә ахунд Әхмәтхаҗи Рахманколый йортыннан ике йорт аша; Һибәтнең кызларының балалары Биктимеревләр кулындадыр. Ул вакыт беренче мәхәлләдә имам булган Зариф бин Габделҗәмил, метрика дәфтәренә сахибе тәрҗемәнең вилядәте[1] хакында болай дип язган: «Атасы лашманчы[2] Әхмәт; анасы Сәгыйдәбану».

Габделвәлинең анасы булган Сәгыйдәбану – Мәхмүд Габдеррәшит угылы Әбүбәкиров кызыдыр. Бу исә Казан өязендәге Сабабаш[3] авылыннандыр.

Сахибе тәрҗемәнең тәүге хатыны Троицкилы Мәүдүдә Хәсән кызыдыр. Моннан Габдерахман вә Хәкимҗан исемле угыллары, Фатиха вә Маһибәдәр атлы кызлары булган. Болардан Хәкимҗан 17–18 яшьләрендә вафат булган; Габдерахман соң көннәрендә Петропавел шәһәрендә торып, шунда үлгән. Моннан, Хәдичә Хәкимҗан кызыннан туган бер угыл калган. Маһибәдәр Троицкида иргә барып Закир исемле бер угыл калдырып вафат булган. Закир, инде өйләнгән, Ташкент шәһәрендә тора. Фатиха Казан сәүдәгәре Сөләйман Аитовка[4] никахланган иде. Бу көндә Фатиха ханым Аитова үзенең атаклы кызлар мәктәбе белән мәгъруфтыр[5]. Сахибе тәрҗемә, Мәүдүдәне 1883 нче ел декабрь 12 сендә талак кылган; ул хәзер Казанда, кызы Фатиха ханым янында торадыр.

Икенче хатыны – Норма[6] авылының Мөхәммәткамал кызы Гайшәдер. Моннан Мөхәммәтгали исемле бер угылы булып, Гайшә бу көндә шуның кулында торадыр.

Өченче хатыны – Әшраф Хәкимҗан бин Гайса кызыдыр. Моннан Мулламөхәммәт, Габделгазиз исемле угыллары, Хәдичә

[1] вилядәт – туу, дөньяга килү.

[2] Лашманчы – урман кисүче.

[3] Сабабаш авылы, Саба районында, район үзәгеннән 11 км көнчыгышрак, Мишә елгасының уң кушылдыгы Казкаш суы буенда. Казан ханлыгы дәверендә нигез салына.

[4] Аитов Сөләйман Мөхәммәтҗан улы (1862–1922) – сәүдәгәр, иганәче, Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы (1896).

[5] мәгъруф – танылган, билгеле булган.

[6] Ике Норма авылы билгеле: 1) Балтач районында, район үзәгеннән 4 км көнчыгышрак, Шушма елгасының уң кушылдыгы Норма суы буенда. Казан ханлыгы дәвереннән мәгълүм; 2) Мамадыш районында, район үзәгеннән 24 км көнбатышрак, Омар елгасының сул кушылдыгы Кирмән суы буенда. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына.

исемле кызы бардыр. Әшраф бу көндә ошбу угылларының кулында торадыр.

* * *

Габделвәли 2 нче мәхәлләдәге мәдрәсәдә Әхмәт хәзрәт Халид угылы заманында, Верхнеурал өязе Илче авылының Юлмөхәммәт вә Гариф исемле хәлфәләрдән укыган. Татарча укырга, язарга белә иде. Үзе «Дәляил әл-хәйрат шәрхе», «Кәрһ Давыд»ны, «Мөхәммәдия» һәм «Алты бармак» китапларын бик сөеп моталәга[1] итә торган булган. Сәүдәгә бирелеп киткәнлектән, укып гыйлем вә фикер даирәсен[2] киңәйтергә тырышканлыгы беленми. Остаз алдында укуы аз, моталәгасе юк дәрәҗәсендә булса да, ул башлы вә тәдбирле[3] кешеләр җөмләсеннән санала иде. Русча укырга да, язарга да белми; ләкин сәүдәгә тәгаллекълы[4] эшләрдә хаҗәт үтәрлек кадәр сөйләшә белә иде. «Тәрҗеман» газетасын[5] укыганлыгы беленмәсә дә, русча газеталарны укытып, сугыш, политика вә кызыклы вөкугатка даир[6] хәбәрләрне тыңлаштыргалый торган булган.

Исәп-хисапка шәп вә җитез; мәгънәсе илә «сәүдәгәр»; төрле яңа эшләр башларга җәсарәтле[7] булган.

Сахибе тәрҗемә, бәгъзебер үзенә мөшкелрәк күренгән хосусый эшләрендә һәм мәчет-мәдрәсә салдыру, уку вә укытуга ярдәм итү вә шуның кебек җәмәгать эшләрендә ахунд Әхмәтхаҗи Рахманколый[8], дамелла Мөхәммәт Бикмати вә шәех Зәйнулла Рәсүли[9] белән киңәш итә торган булган.

## IV

*Мәчетләр бина вә тәгъмир иттерүе – ысулы җәдидәнең таралуына хезмәтләре – «Мәшәкател мәсабих»[10] бастыруы – мөфти Солтанов[11] белән Петербургка баруы – Троицки халкы арасында тоткан мәүкыйгы[12] – хәзерге борадәран Яушевлар фирмасы – сахибе тәрҗемәнең вафаты.*

---

[1] моталәга – уку, өйрәнү.

[2] даирә – кругозор.

[3] тәдбир – эшнең ахырын уйлап эшләү.

[4] сәүдәгә тәгаллекълы – сәүдәгә бәйләнешле.

[5] «Тәрҗеман» – сәяси, фәнни һәм әдәби газета. 1883–1918 елларда Бакчасарай шәһәрендә (Кырым) төрки-татар телендә нәшер ителә. Нашире һәм мөхәррире И. Гаспринский (1851–1914).

[6] вөкугатка даир – вакыйгаларга караган.

[7] җәсарәтле – батыр, кыю.

[8] Рахманкулов Әхмәдһади Габделзакир улы (1837–1921), шәех, ахун (1890 елдан), Троицкий 1 нче мәчетенең имам-хатыйбы.

[9] Рәсүли (Рәсүлев) Зәйнулла (Зәйнулла ишан) (1833–1917) – мөдәррис, ишан, Россиядә иң абруйлы мөселман руханиларының берсе.

[10] «Мәшәкател мәсабих» – русча тәрҗемә иткәндә «Трудности просвещения» исемле китап.

[11] Солтанов Мөхәммәдьяр Мөхәммәтшәриф улы (1836–1915) 1886–1915 елларда мөфти булып тора.

[12] Мәүкыйгы – урыны.

Сахибе тәрҗемә үз халкыбызга мал белән изгелек иткән кешеләр җөмләсеннәндер. Ул Казан губернасында, Троицки вә әтрафында байтак яңа мәчетләр салдырган вә бәгъзе берәүләрен тәгъмир иттергән. Троицки өязе Звериноголовский вә Борхан авылы мәчетләре һәм олуг вә мәһабәт[1] Кустанай мәчете, башлыгы сахибе тәрҗемә булган Яушлар тиҗарәтханәсенең яңадан салдырган мәчетләрнең бәгъзеләредер.

Троицкида татар балаларына махсус русский класс ачарга рөхсәт чыгарту вә шул ук шәһәрдә мөселман җәмгыяте хәйриясе тәэсис итү[2] хакында бик зур хезмәт вә иҗтиһадлар[3] иткән вә бу ике файдалы мөәссәсә[4] мәйданга чыгарылган.

Сахибе тәрҗемәнең иң зур хезмәте – Троицки вә әтрафында ысулы җәдидә белән тәгълимнең таралуына мал белән ярдәм итүедер. Бу якларда моның интишарына[5] аның зур һиммәтләре[6] булган. Ысулы җәдидәнең мәйданга чыгуына вә халкыбыз арасында таралуына үзебездән берничә каләм ияләре, берничә мулла вә мөгаллим, вә берничә байларның хезмәт вә һиммәтләре сәбакать[7] иткәнлеге мәгълүмдер. Менә Габделвәли Яушев та шундый байларның берседер. Минем карашымда, аның бу хезмәте мәчетләр салдыру вә төзәттерүеннән әллә ничә кат мөһим вә олугтыр. Бездә мәчет салдыручы, мәчет төзәттерүче, хиҗаз фәкыйрьләренә[8] садакалар җибәрүче, «Сагълам» теләнчеләрен капка төбенә җыеп зәкят өләшүче вә бәдәл[9] хаж белән васыять итүче байлар бик күп булганнар. Боларның «изгелекләре» гел бертөрле булганлыктан, вә милләтебезнең хәяте вә бәкасы[10] өчен бер тиенлек ярдәм итәчәк эшләр булмаганлыктан, халкыбызда һичбер төрле яхшы әсәр күрсәтә алмаганнар гына түгел, бәлки кайберләре начар әсәрләр күрсәткәннәр. Милләтләрнең хәят вә бәкасында ибтидаи[11] мәктәпләрнең нинди мөһим урын ишгаль[12] итүләре, иске мәктәпләребезнең ни дәрәҗәдә черек вә әсассыз булулары, ысулы җәдидә аркасында ибтидаи мәктәпләребезнең күзгә күренерлек рәвештә юлга салынулары вә яңа һәм файдалы юньгә китүләре бәсыйрәт[13] ияләренә ачык мәгълүм булгач, Гәбделвәли байның ибтидаи мәктәпләрнең төзелүе юлында иткән хезмәт вә

---

[1] мәһабәт – зур, шәп.
[2] тәэсис итү – оештыру.
[3] иҗтиһад – тырышлык.
[4] мөәссәсә – оешма, җәмгыять.
[5] интишар – таралу.
[6] һиммәт – тырышлык.
[7] сәбакать – беренчелек.
[8] Хиҗаз фәкыйрьләре – мохтаҗлар.
[9] бәдәл – алмаштырырга яраклы.
[10] бәка – мәңгелек.
[11] ибтидаи – башлангыч.
[12] ишгаль – берәр төрле эш белән шөгыльләнү.
[13] бәсыйрәт – аңлылык, алдан күрүчәнлек.

ярдәмнәрен ничек мөһим вә олуг санамаска кирәк?

Ысулы җәдидәнең гамәлгә куелуы вә таралуына мал белән хезмәт иткән кешеләр сафка тезелгән тәкъдирдә Әхмәт бай Хөсәеневнең имам урынын тотачагында шөбһә юк. Ләкин Габделвәли дә бу сафның мөһим күрекле бер урынын ишгаль итәчәгендә шөбһәләнергә ярамый. Ысулы җәдидәнең тарихын язучылар моны онытмасыннар!

Ысулы җәдидә мәктәпләренә Габделвәлинең кесәсеннән берничә меңнәр сарыф кылыну өстенә, ул вә ярдәмчеләре үз файдасын үзе белмәгән татарларга вә кирегә беткән бәгъзе муллаларга «яңача укытуны» кабул иттерү юлында да күп мәшәкать вә михнәтләр күргәннәр.

Ахунд Рахманколый хәзрәтләре башлап ысулы җәдидәне гамәлгә кую нияте белән үз хәлфәләреннән Мөхәммәтзакир Ваһаповны (бу көндә Җидесу вилаятендә Тукмак[1] шәһәрендә тора) ысулы тәгълим[2] күрер өчен Истанбулга[3] җибәргәндә аңа кирәк булган мәсарифнең[4] зур бер өлешен Габделвәли биргән. Ул кайтып, берничә ысулы җәдидә мәктәбен ачып укыта башлагач, сахибе тәрҗемә беренче мәхәллә хозурындагы шул мәктәпнең мөгаллимнәренә айга 50 сум мәгаш[5] бирә башлаган. Троицкиның башка мәхәлләләрендә дә ысулы җәдидә мәктәпләре ачылып укытулар башланганнан соң, ул мәктәпләрнең мөгаллимнәренә дә мәгаш бирергә керешкән; хәтта Троицки вә Чиләбе өязендәге бәгъзебер авылларда да мәктәпләр ачтырып мәгашләр биргәләгән. Бу рәвешчә мәктәпләргә ярдәм итүе үзе үлгәнче дәвам иткән.

* * *

«Мәшәкател» бастыруы – 1892–93 нче елларда мөселманнарның дини китапларын бастыруны тыю хакында чиктән тыш инсафсызлыклар башлангач, Русия мөселманнары арасында күңелсезлек, хәфа вә хәфалану булдыгы мәгъруфтыр. Менә бу хәл, мөселманнарның күп торган шәһәрләрнең берсе булган Троицкида да күрелгән. Шушы эш хакында тиешле урыннарга мөрәҗәгать итәр өчен делегатлар сайлап пайтәхеткә[6] җибәрү фикерен сахибе тәрҗемә кузгаткан. Бәс, ахунд Әхмәтхаҗи Рахманколый белән Мулламөхәммәт Бикмати Троицки мөселманнарыннан вәкил сыйфаты илә чыгып киткәннәр, китешли Уфага кереп, Әбүсогуд мирза Әхтәмевне[7] алганнар да Петербургка юнәл-

---

[1] Тукмак шәһәре Җидесу (Семиречье) өлкәсендә, хәзерге вакытта Кыргызстан Республикасына керә.

[2] тәгълим – белем алу.

[3] Истанбул – Госманлы дәүләтенең башкаласы.

[4] мәсариф – тотылган акча, чыгым.

[5] мәгаш – эш хакы.

[6] пайтәхет – башкала.

[7] Әхтәмев Әбүсогуд Габделхаликъ улы (1843–1918 дән соң), хокук белгече, эре җирбиләүче, «Иттифакъ әл-мөслимин» партисен оештыручыларның берсе. 1 нче Дәүләт Думасы депутаты (1906). Бөтенроссия мөселманнарының беренче съездын оештыручыларның берсе.

гәннәр. Шул чорда пайтәхеткә башка шәһәр мөселманнарының вәкилләре дә килгәннәр икән. Ахунд Рахманколыйның сөйләвенә караганда: мөселманнарның шулай аһ-ваһ итеп йөргәннәре заманнарында Петербург ахундының теге вәкилләр белән шаярулары, назлану (каприз)лары, атлаган саен алтын шыңгырдавына колак салуы тарихыбызга язылганда хәлфәләребезне бер җәһәттән[1] көлдерерлек вә бер җәһәттән елатырлык хәлләрдер.

امور تضحك السفهاء منه و يبكي
من عواقبها اللبي[2]

Матбагачы Бораганский[3] ахунд Рахманколыйдан басар өчен китап сораган. Ахунд үз иптәше Мулламөхәммәт хәзрәт белән «Мәшәкател мосабих»ны тәкъдим иткәннәр. Хәлбуки аннан элек шул хәлендә бу китапны басарга рөхсәт бирелмәгән икән. Ләкин бу юлы, бер яктан, Бораганскийның ялварулары вә, бер яктан, Троицки вәкилләренең кулларыннан килгән тәдбирләрдә[4] кимчелек итмәүләре таш бәгырьләрне йомшаткан вә «Мәшәкател»не басарга рөхсәт бирелгән. Шушы «Мәшәкател», сахибе тәрҗемәнең хәраҗаты[5] белән басылган. 1000 нөсхә басканнар, 6000 сум акча тотылган. Китап бик нәфис вә мөкәммәл[6] рәвештә басылган ки, өстенә карап кинәнеп торырлыктыр.

Ошбу «Мәшәкател мосабих» нөсхәсенең[7] баш ягына «Рөхсәт литабигъ Санкт-Петербург фи маһ[8] сентябрь 13, сәнәт мәсихият[9] 1893; фи маһ рабигыл әүвәл 3, сәнәт хиҗрия 1311. Фи әл-матбагъ әл-Ильяс мирза Борагани әл-Кырыми фи Санкт-Петербург» дип басылган. Әмма соңгы битендә:

" فقد انطبع هذا الكتاب الشريف
بسعي.........
بلدة الترويسكي أحدهما سمي حبيب الله
على مابشر به روح الله على مانطق به القرآن
الحكيم [10] وثانيهما أيضا سمي حبيب الله على
ماجاء في مواضيع من تنزيل العزيز الرحيم
[11] وكان هذا الكتاب الشريف من السابيقين
في بلاد الهند مطبوعا ولم يكن في هذا الديار
مطبوعا . فشمر العزيزان المذكوران النبيل
باهتمامهما في طبعه وتمثيله في الدولة
الروسية فتيسر هذه المشكواة الشريف كاملا
مرغوبا مطبوعا في مطبعة الياس ميرزا

[1] Бер җәһәттән – бер яктан.

[2] Гарәп мәкале: «Шундый эшләр бардыр ки, аларның нәтиҗәләреннән ахмаклар көлер, ә зирәк акыл ияләре еглар», гадиләштергән варианты: «Ахмак көлгән нәрсәдән акыллы елар».

[3] Ильяс мирза Бораганский (1852–1920 еллар азагы), нашир, китап басу остасы, педагог. 1894–1910 елларда Санкт-Петербургта хосусый татар матбагасы тота.

[4] тәдбирләр – тиешле чаралар.

[5] хәраҗат – чыгымнар.

[6] мөкәммәл – тулы, бөтен.

[7] нөсхә – экземпляр.

[8] маһ – ай.

[9] сәнәт мәсихият – хрестиан календаре буенча.

[10] Әхмәтхаҗи ахундны ирадә итә. (Автор искәрмәсе.)

[11] Мөхәммәд хәзрәт Бикматины касд итә. (Автор искәрмәсе.)

البورغاني القريمي في سانكت بيتربورغ سنة 1895 بالميلادية وسنة 1313 بالهجرية [1]

дип басылган; вә шул ук соңгы битендә ахунд хәзрәт Рахманколыйның әйтүенә күрә, цензордан махсус рөхсәт алып, штемпель белән: «Габделвәли Әхмәтҗан угылы Яушевның хәраҗаты белән» гыйбарәте беркетелгән.

1895 нче ел мөфти Солтанов, ахунд Рахманколый белән бергә сахибе тәрҗемә, падишаһыбыз Николай Александр угылының[2] тәхеткә утыруын котлар өчен Петербургка барган вә шушы ике юлдаш белән бәрабәр Кышкы Дворецта патша хозурына кабул ителгән вә аның исеменнән императрицага 10000 (ун мең) сумлык мех һәдия[3] тәкъдим ителгән.

* * *

Габделвәли, Троицкида кирәк татарлар, кирәк урыслар арасында бик мөһим урын тоткан. Шәһәрнең мөһим эш вә мәсьәләләре хакында аның киңәшеннән башка эш кылынмаган. Татарлар, кирәк сәүдә хосусларында, кирәк башка мөһим вә гомуми эшләрдә аңа мөрәҗәгать итеп, киңәшә вә гакыл сорый торган булганнар; аның рәэ[4] вә сүзләре бик мәкъбүл[5] вә могтәбәр[6] тотылган. Хәтта Троицкиның әтрафындагы кешеләр дә аның мәслихәт вә гакылыннан файдаланганнар.

Сахибе тәрҗемәгә садакате вә сәүдә эшләрендәге сәбат[7] вә гайрәте һәм кайбер мал вә мөтәгалләренең мөкәммәл[8] вә шәплеге өчен хөкүмәт тарафыннан берничә медальләр ингам[9] ителгән иде.

Ул үлгән көненә кадәр сәүдә эшләрен «Габделвәли Әхмәтҗан угылы Яушев вә борадәрләренең тиҗарәтханәсе» фирмасы астында карендәшләре Мөхәммәтшәриф вә Муллагали Яушевлар белән бергә йөрткән. Ул үлгәч, 4–5 айдан соң фирманың исемен «Торговый дом братьев Яушевых» («Борадәран Яушевлар тиҗарәтханәсе») исеменә алмаштырганнар. Эшләре көннән-көн зурайган, сәүдә мәйданнары киңәйгән. Бу тиҗарәтханәнең хәзерге әгъзалары Мул-

---

[1] Ошбу Изге Китап басылды Троицкидагы ике кямил галимнең, ике мөдәрриснең тырышлыгы белән. Аларның берсе Хәбибулла, Аллаһның рухы аны шатландырсын Коръән Кәримдә ул хакта әйтелгәнчә, икенчесе шулай ук Хәбибулла әл-Газиз әр-Рәхимнең Тәнзиленнән килгәнчә. Бу Изге Китап Һиндстанда аннан элек басылган ике китаптандыр һәм дә ул бу илдә һич басылмаган иде. Ошбу искә алынган шәрәфле икәү аны бастырырга һәм Русия илендә аны тәкъдир кылырга ашыктылар һәм дә ошбу әл-Мишкят әш-Шәриф җиңел кылынды кямил вә тиешле сурәттә басылып Илйас-мирза әл-бургани әл-Кәрими матбагасында Санкт-Петербургта 1895 елда миладича һәм 1313 елда һиҗри белән.

[2] Романов Николай Александрович (1868–1918) Россия империясенең падишаһы.

[3] һәдия – бүләк.

[4] рәэ – фикере, карашы.

[5] мәкъбүл – кабул ителгән.

[6] могтәбәр – игътибарлы, хөрмәтле.

[7] сәбат – фикердә, эштә нык торучанлык.

[8] мөкәммәл – тәмамланган, тулылаштырылган.

[9] ингам – сыйлау, яхшылык итү.

лагали Әхмәтҗан угылы Яушев (фирманың патроны), Габделвәлинең ике угылы: Мулламөхәммәт вә Габделгазиз һәм Мөхәммәтшәриф угылы Латыйф Яушевлардыр. Бу фирма хәзер дә ма вараэ Уралдагы[1] фирмаларның иң дәүләтле, могтәбәр, төпле вә ышанычлыларыннан саналадыр. Сәүдәләре һаман көчәя вә табышлары арта барадыр. Дин вә милләт өчен изгелекләре дә юк түгел. Габделвәлинең балалары истикамәтле[2] вә үз эшләрен башкаручы кешеләрдер.

* * *

Сахибе тәрҗемә Габделвәли Яушев 1906 нчы миладида сентябрьнең 13 ндә иртә белән сәгать дүрттә вафат булган. Яше 67 эчендә иде.

Мәрхүм үлгәндә гомум милләт файдасы өчен зур васыятьләр итәргә муаффәкъ була алмаган[3]. Ләкин үзенең хәятендә иткән изгелекләре дә исемен яхшылык белән сагындырырга җитәрлектер. Аллаһу Тәгалә үзенең ризасына мәзъһәр итсен[4]!

**Искәрмәләрне әзерләүдә кулланылган әдәбият**


*Азаматов Д.Д.* Из истории мусульманской благотворительности. Вакуфы на территории европейской части России и Сибири в конце XIX – начале XX вв. Уфа, 2000. С. 52.

*Гизатуллин Р.Н.* Яушевы // Энциклопедия Челябинской области. Челябинск, 2008. С. 588–589.

*Денисов Д.Н, Старостин А.Н., Гизатуллин Р.Н.* Яушевы // 3.Ислам на Урале. Энциклопедический словарь. Москва; Нижний Новгород, 2009. С. 415–418.

*Мустафина Д.* Служилые мурзы Яушевы в XVI–XVII вв. // Гасырлар авазы (Эхо веков). 2004. № 1. С. 32.

Яушевлар // Татар энциклопедия сүзлеге. Казан, 2002. Б. 815.



*Текстны гарәп имласыннан кирилл алфавитына күчерделәр,*
*сүзлекне һәм аңлатмалары әзерләделәр:*
*Казан Федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни*
*китапханә хезмәткәрләре:* ***Шәрәфиева Рәисә Гамир кызы***
*һәм* ***Әл-Хамад Илфира Арслан кызы.***
*Гарәпчәдән тәрҗемәне эшләргә ярдәм иттеләр:*
*тарих фәннәре кандидаты* ***Хәйретдинов Айдар Гарәфетдин улы***
*һәм* ***Гәрәева Нурия Габделәхәт кызы.***


[1] Ма вараэ Уралдагы – Уралның аръягы.
[2] истикамәт – турылык, дөрес юнәлеш.
[3] Муаффәкъ була алмаган – булдыра алмаган.
[4] Мәзъһәр итсен – булдырсын.